# Йосыпова Фирая Шәйхенур кызы




Йосыпова Фирая Шәйхенур кызы 1949 нчы елда Мөслим районы Яңа Сәет авылында туа. Мари Буләр сигезьеллык мәктәбендә укый. 1967 нче елда Күбәк урта мәктәбен тәмамлый. КДУның тарих-филология факультетын тәмамлый. Яңа Үрәзмәт, Октябрь авылларында укыта. 1972 нче елдан Мөслим урта мәктәбендә эшли башлый. 1974 нче елдан мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта. (2000 нче елга кадәр). 1986 нчы елда “Методист –укытучы” категориясе бирелә. 1993 нче һәм 1998 нче елда “Әйдәп баручы укытучы” дигән квалифакацион категориягә лаек була. 1999 нчы елда “Татарстан Республикасының атказанган укытучысы” дигән исем бирелә. 2000-2005 нче елларда Алабуга шәһәренең 11 нче мәктәбендә директор булып эшли. Лаеклы ялга чыкканнан соң Алабуга мәдәният училищесында татар теле һәм әдәбияты укыта. Эшләү дәверендә Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Агитатор, лектор, пропагандист хезмәтләрен башкара. Берничә мәртәбә халык депутатларының Мөслим авыл Советы депутаты итеп сайлана. Район хатын-кызлар советы әгъзасы була. 1984-85 нче уку елыннан район күләмендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик берләшмәсен җитәкли. Татар теле һәм әдәбияты кабинеты республика күләмендәге конкурста җиңеп, видеомагнитафон белән бүләкләнә. Хезмәт дәверендә 5 мәртәбә класс җитәкчесе булып, укучыларны олы тормыш юлына чыгарды. (5 чыгарылышның 50 дән артык укучысы татар теле һәм әдәияты буенча укырга керде. Бүгенге көндә дә район мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыталар.) Хәзерге көндә Фирая Шәйхенуровна лаеклы ялда, Хезмәт ветераны, районның иҗтимагый тормышында актив катнаша.